**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2010 елның 24 декабрендәге ПУ-856 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 29 декабрендәге ПУ-892 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1210 номерлы, 2015 елның 9 октябрендәге ПУ-979 номерлы, 2016 елның 30 маендагы ПУ-487 номерлы, 2017 елның 21 апрелендәге ПУ-325 номерлы һәм 2018 елның 13 гыйнварындагы ПУ-30 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы структурасына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 08 май
№ ПУ-361

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның « 08 » маендагы
ПУ-361 номерлы Указына
кушымта

## Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы структурасы

**Министр**

- Муниципаль районнарда, «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге районнарында территориаль органнар
- Министр ярдәмчесе

**Министрның беренче урынбасары**
- Хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге
- Координацияләү һәм контроль бүлеге
- Җир, мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм матди-техник тәэмин итү бүлеге
- Хезмәтне саклауга дәүләт идарәсе бүлеге
- Тармак программаларын үстерү һәм эшләү бүлеге
- Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге

**Министр урынбасары**
- Контроль-ревизия эше бүлеге
- Планлаштыру, финанслау һәм хезмәт өчен түләү бүлеге
- Дәүләт сатып алулары бүлеге

**Министр урынбасары**
- Социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге
- Социаль регистрны формалаштыру бүлеге
- Социаль ярдәм чаралары аудиты бүлеге
- Пенсиягә өстәмә түләү һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү һәм түләү бүлеге
- Халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын координацияләү бүлеге

**Министр урынбасары**
- Социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге
- Хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү бүлеге
- Хезмәт базары һәм дәүләт хезмәтләре мониторингы бүлеге
- Һөнәри белем һәм һөнәри юнәлеш бирү бүлеге

**Министр урынбасары**
- Социаль хезмәт күрсәтү системасын оештыру бүлеге
- Социаль хезмәт күрсәтү методологиясе бүлеге
- Социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге
- Чаралар үткәрүне оештыру бүлеге

**Министр урынбасары**
- Инвалидлар белән эшләү бүлеге
- Мәгълүмати технологияләр, техник хезмәт күрсәтү һәм автоматлаштырылган системаларны эксплуатацияләү, мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлеге
- Иҗтимагый оешмалар белән эшләү бүлеге

**Эшләр идарәчесе**
- Эш башкару бүлеге
- Халык белән эшләү секторы
- Административ-хуҗалык бүлеге

**Юридик бүлек**
- Бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге
- Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге
- Мобилизация әзерлеге, гражданнар оборонасы секторы